اللغة التترية

татар теле

دليل المسلم الجديد، ما هو الإسلام؟

للشيخ د. هيثم سرحان

# Ислам диненә яңа кергән мөселман кешесе өчен кулланма

## Нәрсә ул Ислам?

Syaikh Dr. Haitsam Sarhan

# «Ислам дине нәрсәдән башлана?»

SHEIKH DR. HAYTHAM SARHAAN

татар теле: التتارية

Mahadsunnah.com
Sarhaan.com

MahadSunnah

رِسَالَةٌ مُخْتَصَرَةٌ بِعُنْوَانِ:

# «كَيْفَ أَدْخُلُ فِي الإِسْلاَمِ؟»

مُتَرْجَمَةٌ إِلَى اللُّغَةِ: الروسية

# «Ислам дине нәрсәдән башлана?»

Шәйх Хәйсәм бин Мөхәммәд Сәрхан

Пәйгамбәребез ﷺ мәчете укытучысы һәм «Сөннәт» институты җитәкчесе

mahadsunnah.com

sarhaan.com

**Беренче басма**

[Авторлык хокукларына, китапның эчтәлеген һич үзгәртмичә,

# Ислам дине нәрсәдән башлана?

| Сорау: | Җавап: |
|---|---|
| Ислам динен кабул итү гамәле җиңелме? | Әйе; Моның өчен һичнинди арадашчыларның булуы да, йолалар үтәлүе дә кирәк түгел. |
| Ислам динен кабул итәргә ашыгыргамы миңа, я булмаса, сабыр итеп, уңайлырак вакыт җиткәнен, проблемаларымның хәл ителгәнен көтәргәме? | Инициатива күрсәтергә кирәк; Чөнки Ислам динен кабул итүне кичектерү яманлыкка китерергә мөмкин. Кеше теләсә кайсы мизгелдә вафат була ала, ә Ислам динен кабул итү – ул керем кебек, инициативаны никадәр күбрәк күрсәтәсең, шулкадәр күбрәк уңышка ирешәсең. |
| Ислам динен кабул итәсе килгән кешегә нәрсә эшләргә? | Аңа шәһәдәт кәлимәсен әйтү җитә: «Шәһәдәт бирәм: Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы илаһ юк, һәм шәһәдәт бирәм: Мөхәммәд — Аның колы һәм Рәсүле». |
| Шәһәдәт кәлимәсен нинди телдә әйтергә? | Гарәпчә әйтү мәҗбүри түгел, кайсы телне яхшы беләсең, шул телдә әйтергә мөмкин. |
| Әгәр кеше шәһәдәт кәлимәсенең мәгънәсен аңламаса, ул аны әйтәме? | Юк; Башта шәһәдәт кәлимәсенең мәгънәсен аңларга, аның эчтәлегенә инанырга һәм аның нигезендә гамәл кылырга кирәк. |

| Сорау: | Җавап: |
|---|---|
| «Шәһәдә» (шәһәдәт бирәм) сүзе нәрсәне аңлата? | Ул «Йөрәгем белән кабул итәм, телем белән әйтәм һәм шуның нигезендә гамәл кылам», - дигәнне аңлата. |
| «Лә иләһә иллә Аллаһ» кәлимәсе нәрсәне аңлата? | Ул: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы булган иләһ юк», - дигәнне аңлата. |
| «Мөхәммәд — Аның колы һәм рәсүле» җөмләсе нәрсәне аңлата? | Ул: «Мөхәммәд – Аллаһның колы, һәм аңа гыйбадәт кылырга ярамый, ул Рәсүл, һәм ул һичкайчан ялганламый», - дигәнне аңлата. Шәһәдәт кәлимәсе ул әйткән сүзләргә, кылырга чакырган гыйбадәткә ышанырга кирәклекне, аның әмерләренә буйсынырга һәм ул тыйган, кисәткән гамәлләрдән тыелырга, аның Сөннәтенә иярергә кирәклекне төшендерә. |
| Мин шәһәдәт кәлимәсен бик яхшы аңлыйм, хәзер миңа нишләргә? | Минем арттан кабатлагыз: «Шәһәдәт бирәм: Аллаһтан башка гыйбадәткә лаеклы иләһ юк, һәм шәһәдәт бирәм: Мөхәммәд — Аның колы һәм Рәсүле» (Әшһәду ән лә иләһә иллә Аллаһ, уә әшһәду Әннә Мөхәммәдән гәбдуһу уә расулюху). |
| Мин хәзер мөселманмы? | Әйе, ӘлхәмдулиЛләһ, бу сезгә Аллаһның рәхмәте. |
| Миңа, мөселман буларак, сез нинди киңәш бирер идегез? | Мин сезгә Аллаһтан Аның динендә нык булуны сорап, динне аңлауда яхшы иптәшләр очравын, Аллаһның рәхмәте белән Исламны өйрәнүдә ныклык, сабырлык сорап дога кылырга киңәш итәр идем. |
| Иң яхшы дога нинди дога ул? | «Безне туры юлга күндер» (Иһдинә сыраталь мустәкыйм) [әл-Фәтиха] |
| Иң җиңел зикер нинди зикер? | Иң җиңел зикер ул – (Бисми-Лләһ), ул мәчеткә кергәндә, мәчеттән һәм өйдән |

| Сорау: | Җавап: |
|---|---|
| | чыкканда, Коръән укыганда, юыну бүлмәсенә кергәндә, киемнәрне салганда, тәһәрәт ала башлаганда, ашарга, эчәргә тотынганчы һәм башка гамәлләрне кылыр алдыннан әйтелә. |
| Ислам динен кабул иткәнчегә кадәр кылынган гөнаһларымның хөкеме нинди? | Ислам динен кабул иткәнчегә кадәр кылынган гөнаһлар сөртелә, әмма кешеләрнең синең тарафтан бозылган хокуклары искәрмә булып тора, аларның хокуклары кире кайтарылырга тиеш. |
| Шәһәдәт кәлимәсен әйткәч миңа нишләргә? | Госел коенырга кирәк. |
| Госел коену ни өчен кирәк? | Беренчедән: Мөселманнар: «Ни өчен?/Нигә?» кебек сораулар бирми, алар: «Без ишеттек һәм буйсындык», - диләр [Ән-Нур: 51].<br><br>Икенчедән: тәнне тыштан чистартмыйча торып, эчтән чистарыну (калебне чистарту) мөмкин түгел. |
| Яхшы, ә госелне ничек коеналар? | Калебтә госел коенырга җыенуыңа ният булырга тиеш, шуннан «Бисми-Лләһ», - әйтелә. Тәннең бөтен өлеше дә су белән юылырга тиеш (шулай ук авыз белән борынны да чайкатырга кирәк). |
| Госел коенганнан соң нишләргә? | Әгәр намаз вакыты җитсә, Аллаһның теләге һәм рәхмәте белән намаз укыгыз. |
| Намаз уку авыр булачакмы? Намазда бит мин аңламый торган сүзләр һәм хәрәкәтләр бар. | Ислам- ул җиңеллек дине, авырлык дине түгел, шуңа күрә Аллаһка барча мактау һәм олугълаулар. |
| Намазны ничек укырга? | Сез, намаз уку рәвешен төрле телләрдә аңлатып язылган видеоларны карап, минем белән бергә, миңа ияреп намаз укыячаксыз. Видеоларны сез әлеге |

| Сорау: | Җавап: |
|---|---|
| | китапның соңында бирелгән сылтамалар аша үтеп, «Институт Сунны» дип аталучы интернет каналдан карый алачаксыз. |
| Ә намаздан соң нишләргә? | Сез Исламның нигезе булган биш баганаы, ә аннан соң иман әркәннәрен һәм башкаларны өйрәнергә тиешсез. Болар барысы да Сезнең исламыгызны иманыгызны дәлилләү өчен кирәк. |
| Исламны өйрәнү өчен нинди интернет сайтларга керергә тәкъдим итәсез? | Мин Сезгә Ислам һәм Сөннәтне өйрәнүче олугъ галимнәр сайтларына, Согуд Гарәпстаны Корольлеге интернет берләшмәсе битенә кереп өйрәнергә киңәш итәм. |
| Мөселман булмаган туганнарым белән үз-үземне ничек тотарга миңа? | Сез алар белән пәйгамбәребез, Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын, үрнәгендә мөгамәлә кылырга тиешсез. Ул мөселман булмаган туганнарын үзенең теле, үзенең әхлагы һәм үзенең гамәлләре белән Ислам диненә чакырган. |
| Ислам динен кабул итәргә теләп тә, бу хакта үзенең гаиләсенә әйтергә теләмәүчеләр бар, мондый очракларда нишләргә? | Ислам динен кабул иткән кеше кемгәдер үзенең Ислам дине кабул итүе хакында әйтергә бурычлы түгел, чөнки аның бу гамәле Аллаһ белән аның арасында булган мөгамәлә. |
| Исламда иң яхшы китап нинди китап? | Иң яхшы китап ул – Изге Корьән китабы, чөнки ул Аллаһ Тәгаләнең сүзләре. |
| Корьәндәге иң әһәмиятле сүрә нинди сүрә? | Иң әһәмиятле сүрә - «Әл-Фәтиха», һәм нәкъ менә шуның өчен дә без аның намазның һәр рәкәгатендә укыйбыз. |
| Корьәндәге иң бөек аять нинди аять? | Корьәннең иң бөек аяте – «Аят әл Көрси». |

| Сорау: | Җавап: |
|---|---|
| Мин Коръәнне ничек укый алам? | Коръәнне өйрәнеп һәм аның дөрес укылышын, мәсәлән, шәех Хузәйфа, әл-Хусари һәм башка Коръән укучыларны тыңлап. |
| Коръәнне ничек аңларга? | Коръәнне аның мәгънәләрен аңлаткан танылган галимнәр тарафыннан язылган тәфсир китапларын укып аңларга мөмкин. |
| Коръән тәфсирен мин каян таба алам? | Сезгә Мәдинә шәһәрендәге Коръән бастыру комплексына барырга киңәш бирәм. |
| Коръәнне укыганнан соң тагын нәрсәләр укырга киңәш итәр идегез? | Пәйгамбәребезнең, Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын, ышанычлы хәдисләрен укыгыз. |
| Хәдисләр буенча нинди китап яхшырак? | Иң яхшы һәм иң дөрес хәдисләр китабы ул – «Сахих әл-Бухари». Мөселманнар әлеге фикер белән килешә һәм әлеге китапка хөрмәт белән карый, ул галимнәр тарафыннан да расланган. Әлеге китапның соңында бирелгән сылтамалар аша үтеп, хәдисләр китабы белән дә таныша аласыз. |
| Пәйгамбәребезнең сөннәтендә, Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын, кайсы хәдис мөһимрәк? | Хәдисләрнең иң мөһиме – Җәбраил галәйис-сәлам хәдисе, әлеге хәдистә диннең өч баганасы Ислам, Иман, Ихсан хакында аңлатыла. |
| Әгәр дә мин Ислам динен өйрәнә алмам, дип курыксам? | Курыкмагыз, һәрвакытта та Аллаһка сыенгыгыз һәм Аннан гына сорагыз, һәм Ул сезнең барча авырлыкларыгызда да ярдәм итәр, чөнки, нигездә, Аллаһның дине җиңел дин. Аллаһтан Ул Үзе яраткан һәм риза булган нәрсәләрдә сезгә уңыш бирүен сорап дога кылам. |

| Сорау: | Җавап: |
| --- | --- |
| | Сез әлеге китапның ахырында бирелгән сылтама аша үтеп, теләсә-кайсы вакытта безнең «Сөннәт» институтында онлайн рәвештә бушка гыйлем ала аласыз.<br><br>Һәм китапны мин Аллаһның рәсүле, Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын, сүзләре белән тәмамлыйсым килә: ***«Сиңа файдага булчак нәрсәләргә омтыл, Аллаһтан ярдәм сора һәм бу гамәлләрдә йомшаклык күрсәтмә».*** |

# «Сөннәт» Институты каналына сылтамалар

Телеграмм каналга сылтама:

Фейсбук каналына сылтама:

«Сөннәт» институты сайты:

Ватсапка сылтама:

Твиттерга (X) сылтама:

Инстаграмга сылтама:

Китаплар:

YouTube канал:

Татарча التترية

# 3 Тәүхиднең төрләре

Бөек Аллаһны Аңа гына хас булган хакимлектә, илаһылыкта һәм исем-сыйфатларында берләү

Тәүхиднең өч төре бар.

### Тәүхид әсмә үә-с-сыйфат

Аллаһны Ул Үзе турында раслаган нәрсәләрне раслап, инкарь иткән нәрсәләрне инкарь итеп, Үз китабында яки Аның илчесе аша хәбәр ителгән исем-сыйфатларында берләү. Бу исем сыйфатларны бер нәрсәгә дә охшатмыйбыз, яки үзгәртеп бозмыйбыз, кире какмыйбыз һәм ничек дип сорау бирмибез.

### Тәүхид әл-улюхиййә

Аллаһны гыйбадәттә ягъни колларының гамәлләрендә берләү.

### Тәүхид әр-рубубийә (хакимлек)

Ул - бөек Аллаһны Аның гамәлләрендә яки барлыкка китерүдә, хакимлектә һәм идарә итүдә берләү.

# Диннең өч дәрәҗәсе бар.

## Ихсән

Ихсән ул – Аллаһны күргән кебек гыйбадәт кылу, һәм әгәр син Аны күрмәсәң Ул сине күрә икәнен белеп тору.

**Бер баганаың ике дәрәҗәсе:**

1. Күрү гыйбадәте – ул Аллаһка Аны күргән шикелле гыйбадәт кылу
2. Өстеңнән күзәтү гыйбадәте – син Аллаһны күрмәсәң, Ул сине күреп торганын белеп гыйбадәт кылу.

## Иман

Иман – ул тел белән әйтү, йөрәк белән инану һәм тән әгъзалары белән гамәл кылу. Иман арта һәм кими.

**Иманның баганалары алты:**

1. Аллаһка ышану
2. Аның фәрештәләренә ышану
3. Аның китапларына ышану
4. Аның илчеләренә ышану
5. Кыямәт көненә ышану
6. Тәкъдиргә ышану

## Ислам

Ислам – ул Аллаһка тәүхид аша буйсыну, буйсынучылык аша Аңа иярү һәм ширектән һәм аның әһелләреннән баш тарту.

**Исламның 5 баганасы:**

1. Ике шаһәдәтнамә
2. Намаз
3. Зәкәт
4. Ураза
5. Хаҗ кылырга мөмкинлек булса хаҗ кылу

# 4 Тыелган нәрсәләрнең төрләре:

### Кече гөнаһлар

Олы гөнаһлардан кала башка гөнаһлар

Олы гөнаһлар тәүбә аша юкка чыга, кече гөнаһларны гел кылу олы гөнаһларга китерә.

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: "Гөнаһларга салкын караш белән карамагыз, чынлыкта, алар кешедә аны һәлак иткәнчегә кадәр җыелып барачак".

### Олы гөнаһлар

Хас җәза бирелгән барлык гөнаһ

Сихер, ата-анага буйсынмау, риба, зина кылу, ир-атларның бер-берсе белән җенси мөнәсәбәткә керү, алдау, исерткеч эчемлекләр эчү, урлау, гайбәт сату, бер хаксызга кешене үтерү, ятимнәр малын ашау.

### Кече ширек

Ислам диненнән чыгармый, олы гөнаһларның иң зурысы.

Аллаһ теләде һәм син дигән сүзләр, Аллаһтан башкалар белән ант итү, ширек амулетлары, начар билгеләргә ышану һәм күрәзәчелек, хиромантия һәм саклау сәбәбе дип яки күз тидерүдән саклый дип ышанып төрле бөтиләр элү.

### Олы ширек

Ислам диненнән чыгаручы, һәм әгәр тәүбә итмичә үлеп китсә, гафу ителмәячәк.

Аллаһка тиңдәш китерү, ягъни Аңа дога белән ялварган төсле башкаларга ялвару, яки курку, яки өмет итү, яки Аллаһны яраткан кебек калганнарны ярату, я инде нинди дә булса гыйбадәтне Аллаһтан кала башкаларга багышлау.

# Тәһарәт, тәямүм һәм гөсел алу сыйфатлары 2

## Таһәрат алу тәртибе

Кеше, тәһәрәт алырга ниятләгәннән соң, Аллаһның исеме белән “Бисми-Лләһ” ди; Шуннан соң өч тапкыр кул чукларын юа;



1

Аннан соң уң учына су тутыра, шул суның бер өлешен авызына алып, авыз эчен чайката һәм тәкерә; суның калган өлешен борынына суыра, аннан соң аны сеңгерә, сеңгергән вакытта борынын сул кулының баш һәм имән бармаклары белән сыпыра. Шул рәвешле өч тапкыр эшли.



2

Шуннан өч тапкыр битен юа. Битнең чикләре шул: чәчләр үсә башлаган урыннан алып ияк астына кадәр, ә киңлеккә – бер колактан алып икенчесенә кадәр;



3

Аның соңында терсәкләре белән бергә кулларын (бармак очларыннан алып терсәккә кадәр), башта уңын, аннан сулын юа.



4

Шуннан соң юеш ике учы белән башын сыпыра: маңгайдан алып баш артына кадәр һәм киресенчә, баш артыннан маңгайга кадәр;



5

Аннары юеш имән бармаклары белән колак яфракларының эчен юа;



6

Ахырда өч тапкыр аякларын ашык сөякләренә кадәр тубык тиңентен юа.



7

- Тәһарәт алуда билгеләнгән чикләрне узуга карата шәригать хөкеме?

Тәһарәт алуда билгеләнгән чикләрдән узып китеп, үзеңнән ни дә булса өстәү рөхсәт ителми, мәсәлән, тән әгъзаларын өч тапкырдан да артыграк юу, я булмаса, кулларның терсәктән югарырак өлешен юу, яки аякларны юган вакытта балтырларны юу, яки муенны сыпыру.



8

- Тәһәрәт алып бетергәннән соң :

“Әшхәду әлә иләһә иллә-Ллаһ вәхдәху лә шәрикә ләһ вәәшхәду әннә Мухәммәдән гәбдуху вә расулюх” дип әйтү тиешле. Әт-Тирмизи башка зикерләр дә китерә: “Аллахуммә-дж‘әл-ни мин әт-тәввәбинә вәдж‘әл-ни мин әл-мутатаххирин”

9

- ТӘҺӘРӘТНЕ БОЗУЧЫ ГАМӘЛЛӘР :

1- Җенси органнардан һәм аналь ачыклыктан бүлендекләр чыгу
2- Акылны югалту: бирегә йокы һәм башкалар керә;
3- Дөя итен ашау;

10

## Тәямүм алу сыйфаты

Су булмау яки аны куллану зыян китерү сәбәпле, тән әгъзаларын чистарту мөмкинлеге булмаганда, тәһәрәтне тәяммум алмаштыра. Бу очракта су урынына туфрак кулланыла.

1

Кеше җир белән чистарынуны ният кылганнан соң, “БисмиЛләһ” әйтергә, шуннан соң уч төпләре белән бер тапкыр җиргә сугарга, аннан битен һәм кул аркаларын сыпырырга тиеш.




2

һәм уч төпләре белән җиргә сукканда бармакларны берсеннән берсен аеру да, кул аркаларын сөрткәндә бармак араларын сөртү дә дөрес түгел.



3

## Гөсел алу тәртибе

Госел алырга ният кылу һәм пычраклардан арыну, шуннан соң “БисмиЛләһ” әйтү, бөтен тәнне, куе, шулай ук сирәк чәчләр астындагы тәнне юу, авыз һәм борыны чайкау.

1

- Госел тиешле булган гамәлләр :

1- Җенси якынлык яки башка сәбәп белән эякуляция (мәни чыгу) булу. Шулай ук мәни чыкмыйча җенси якынлык кылу да госелне боза; 2- Хәез һәм нифас каны ага башлау; 3- Үлем, бу шәһидләргә (яу кырында һәлак булучы) кагылмый; 4- Динсез кешенең Исламны кабул итүе;

2

Әзерләүче: Хәйсәм бин Мөхәммәд Дҗәмил Сәрхән Пәйгамбәребез мәчетендәге укытучы һәм
« mahadsunnah.com »

Tatar تتري 01/50

# Пәйгамбәребезнең ﷺ намаз уку сыйфаты 1

Имам һәм ялгыз гына намаз укый торган кеше алдында киртә (сутра) булса әйбәт. Имам артыннан намаз укучының киртәсе булып исә имамның киртәсе хезмәт итә;



Намаз укучы үзенең күз карашын сәҗдә урынына юнәлтә һәм намаз вакытында читкә борылмый;



1

Намаз укучы аякларын җилкәләре киңлегендә куя һәм аларны тышкы яктан тигезли;



2

Намаз укучы намазның барлык шартларын да үтәгәч, "Аллаһу әкбәр" дип намазга керу тәкбирен әйтә. Бу сүзләрне әйткәндә, бармакларны бер-берсе белән тоташтырып һәм уч төпләрен Кыйбла тарафына юнәлтеп, кулларны җилкәләр яки колаклар биеклегенә күтәрә;



3

Шуннан соң ул, уң кул чугын сул кул чугының аркасына, шулай ук беләзеккә һәм беләкләргә куя, яки уң кулы белән сул кулының беләзеген тота;



4

Соңыннан, тәкбирдән соң, намаз башында укылучы зикерләр (әл-истифтах) укылса, яхшы була. Төрлелек өчен, Сөннәттә килгән башка зикерләр укылса, тагын да әйбәтрәк була, һәм әйтә: «Субхәнә-кә, Аллаһуммә, вә бихәмди-кә, вә табәракә-сму-кә вә тә'әләҗәдду-кә вә лә иләһә гайру-ка»

Шуннан соң намаз укучы "Әгузу би-Лләһи минәш-шәйтанир-раҗим" (истигәзә) сүзләрен әйтеп, Аллаһның яклавына сыена;

Шуннан соң: "Би-сми-Лләһи әр-Рахмәни әр-Рахим" сүзләрен әйтә, аннан "Фатиха" сүрәсен, бер генә аятен дә төшереп калдырмыйча, тулаем укый. Аятьләрне бер-бер артлы, рәттән, хәрефләрне, хәрәкәләрне, сүзләрне дөрес итеп әйтеп уку шарт; Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.1. Әл-хә́мду лил-лә́һи ра́ббил-гъа́ләми́н2. Әр-рахмә́нир-рахи́м3. Мә́лики йә́үмид-ди́н4. Иййә́кә нә́гъбуду үә иййә́кә нәстәгъы́йн5. Иһдинә́с-сыйра́таль-мустәкы́йм6. Сыйрата́ль-ләзи́нә әнгъә́мтә гъалә́йһим7. Гә́йриль-мәгду́би гъалә́йһим үә лә́д-да́льлин.

"Фатиха"дан соң "Коръән"нән тагын нәрсә булса да уку әйбәт. Бу очракта истигәзә әйтелми һәм әгәр уку сүрә башыннан башланса, бу очракта "Би-сми-Лләһи әр-Рахмәни әр-Рахим" сүзләрен әйтү кирәк;

5

Шуннан соң намаз укучы: "Аллаһу әкбәр", – ди һәм рөкүгъка китә, һәм кулларын тезләренә куя, бу вакытта куллар терсәкләрдән бөгелми. Аның аркасы исә башы белән бер турыда булырга тиеш. Ул мәҗбүри рәвештә бер генә тапкыр булса да "Субхәнә раббиәл-газыйм" сүзләрен әйтергә тиеш, аннан соң Сөннәттә килгән башка зикер һәм догаларны өстәп әйтсә ярый;



6

Шуннан соң рөкүгътан турайган вакытта, тураеп беткәнче, намаз укучы "Сәмиа'Ллаһу лимән хәмидәһ" сүзләрен әйтә.

Шуннан соң тулысынча тураеп беткәч, ул: "Раббәнә үә ләкәлхәмд", – ди. Шуннан соң ул Сөннәттә килгән башка зикер-догаларны әйтсә, яхшы була;

Моның соңында ул, кулларын күтәрмичә: "Аллаһу әкбр", – ди һәм тәнnең җиде өлеше: маңгай белән борын, уч төпләре, тезләр һәм ике аяк бармакларының эчке өлешләре белән сәҗдә кыла;

Сәҗдә вакытында намаз укучы кулларын ян-яклардан (ягъни алар тәнгә тиеп тормый), корсакны ботлардан, ә ботларны балтырлардан ерагайта, шулай ук терсәкләрне җирдән күтәрә;



7

Ул мәҗбүри рәвештә бер тапкыр гына булса да "Субхәнә раббиәл-әгълә" сүзләрен әйтә, аннан соң Сөннәттә килгән башка зикер һәм догаларны өстәп әйтсә ярый, шулай ук ул әгәр теләсә, башка дога сүзләрен әйтә ала, әмма ул Аллаһка пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) килгән сүзләр белән мөрәҗәгать итсә, тагын да яхшырак була;



8

Шуннан соң ул "Аллаһу әкбәр", – ди һәм җирдә яткан һәм үзенә таба бөкләнгән сул аяк табаны өстенә, ә уң аякның табанын вертикаль рәвешкә китереп һәм аның бармакларын Кыйбла ягына каратып утыра, кулларын ботларының тезләргә якын өлешенә куя – шул рәвешле бөтен намазларда да утырыла. Бары өченче һәм дүртенче рәкәгатьләрдә генә "тауаррук" халәтендә – сул аягын уң аяк балтыры астына кертеп утыру кирәк;



9

Утырып торудан соң намаз укучы "Аллаһу әкбәр", – дип әйтә һәм беренче тапкырдагы кебек үк сәҗдә кыла.Шуннан соң ул "Аллаһу әкбәр", – дип әйтә һәм икенче рәкәгатькә торып баса. Аны беренче рәкәгать кебек үк үти, ләкин икенче рәкәгатьтә намазны ачучы тәкбир әйтелми һәм "истифтах" догасы кылынмый;



Намаз укучы икенче сәҗдәдән күтәрелеп, "тәшәххуд" кылу өчен утыра;

Уң кулының имән бармагын Кыйбла ягына юнәлтә һәм Аллаһтан ярдәм сорап, аны селкетә, ә урта һәм баш бармакларын бөҗра итеп тоташтыра;



Бу вакытта ул мәҗбүри рәвештә "тәшәххуд" һәм "салават" сүзләрен әйтә:
Әттәхияту лилләһи үәс-саләүәти үәт-тайибәт, әссәлә-му гәләйкә әййүһән-нәбийү үә рахмәтүллаһи үә бәракәтүһ, әссәләму галәйнә үә галә гый-бәдилләһис-салихин, әшһәду әллә иләһә иллАллаһү үә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһ. Аллаһүммә салли галә Мүхәммәдин үә галә әли Мүхәммәд, кәмә салләйтә галә Ибраһимә үә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид. Аллаһүммә бәрик галә Мүхәммәдин үә галә әли Мүәммәд, кәмә бәрактә галә Ибраһимә үә галә әли Ибраһимә иннәкә хәмидүм-мәҗид.

Шуннан соң ул Аллаһтан дүрт бәладан: Җәһәннәм газапларыннан, кабер газабыннан, дөнья һәм үлем фетнәсеннән, Дәдҗәл коткысыннан саклану сорый (Аллаһуммә инни ә'узубикә мин 'әзаби джәхәннәм, уа мин 'әзабиль-къабр, уа мин фитнәтиль-мәхья уәль-мәмәт, үә мин шәрри фитнәтильмәсихи-ддәдҗҗәл) , шуннан соң намаз укучы Аллаһка башка дога сүзләре белән мөрәҗәгать итә ала, әмма ул Аллаһка пәйгамбәребездән (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) килгән сүзләр белән мөрәҗәгать итсә, тагын да яхшырак була, мәсәлән: "Йә Аллаһ, тиешле дәрәҗәдә Сине зикер кылырга, Сиңа шөкер итәргә һәм Сиңа гыйбадәт кылырга ярдәм ит миңа!" (Аллаһуммә, ә'ин-ни 'әлә зикри-кә, вә шукри-кә вә хусни 'ибәдәти-кә);

Шуннан соң ул уң якка да, сул якка да сәлам бирә, сәлам биргән вакытта җилкәләр борылмый, бары тик баш кына борыла (баш күтәрелми дә, төшерелми дә) һәм ян-якларга куллар белән күрсәтелми;



10

Әзерләүче : Хәйсәм бин Мөхәммәд Джәмил Сәрхән Пәйгамбәребез мәчетендәге укытучы һәм mahadsunnah.com сайтының җитәкчесе

Татарча التترية

# Зәкәт ике төргә бүленә

**Фарыз**

**Фарыз булган зәкәт икегә бүленә:**

Мөстәһәб (ихтыярый)– ул чын күңелдән Аллаһ ризалыгы өчен малыңны сарыф итү.

## Тән зәкәте(фитр сәдакасы)

бу төр сәдака барлык мөселманга да үәҗиб булып тора, зурысына да, кечесенә дә, ир-атка да, хатын-кызга да, колга да, иреклегә дә.

## Мал зәкәте

ул малыңның шәригать билгеләгән бер өлешен чыгарып, билгеләгән төркемгә сарыф итеп, Аллаһка гыйбадәт кылу. Бу Исламның өченче әркәне булып тора

һәм ул дүрт төргә бүленә:

1 **Алтын-көмештән**



акчадан һәм аларны алмаштыра торган башка нәрсәләрдән зәкәт, акчаның күләме 85 грамм алтын бәясенә, я инде 595 грамм көмеш бәясенә җитәргә тиеш.

2 **Көтүлектә йөрүче терлек**



тулысынча, я инде күп вакытын көтүлектә уздыручы дөя, сыер, сарык кебек мал-туар керә.

3 **Җирдән үсеп**



чыгучы бөртек-ярма.

4 **Сату-алу товары**



сәүдәдә булган барлык товар да керә.

## Зәкәт бирелергә тиеш булган кешеләр:

1 **Фәкыйрьләр**: бернәрсәсе дә булмаган, я инде кайбер нәрсәсе генә булган кешеләр керә.

2 **Мескеннәр**: алар яшәр өчен кирәк яракның яртысын, я инде күбрәген табалар. Мисал өчен ел дәверендә яшәр өчен 200 мең акча кирәк. Фәкыйрь ел буена 100 мең дә, я инде бөтенләй бернәрсә дә таба алмый. Ә мескеннең еллык кереше 100 мең, я инде күбрәк, ләкин 200 меңгә тулмый. Аларның икесенә дә шушы җитмәгән күләм мал бирелә.

3 **Зәкәт эшчеләре**: хөкемәт билгеләгән зәкәтне җыючылар, саклаучылар, бүлүчеләр керә. Һәм аларның Фәкыйрь, яисә мескен булулары шарт булып тормый.

4 **Йөрәкләрне йомшартыр өчен**: бу кешеләрнең Исламга керүен теләп, я инде кемнеңдер явызлыгыннан сакланыр өчен, я инде иманны күтәрер өчен бирелгән мал.

5 **Мөселманнарны азат итү**: а) - Үз-үзен коллыктан сатып алырга теләүче колга, б) - колны азат итүгә, в) - мөселманны әсирлектән азат итүдә.

6 **Әҗәтен кайтара алмаучыга**: шул әҗәтен капларлык мал бирелә.

7 **Аллаһ юлында**: Аллаһ юлында булучыларга

8 **Юлчыга**: юлда булып, юлын дәвам итергә акчасы булмаган мөсафиргә. Мондый кешегә өенә кайтып җитәрлек мал бирелә.

# Ураза ике төргә бүленә:

**Мөстәхәб:** бу ике очрактан кала.

**Үәҗиб:** рамазан аенда һәм үтәлмәгән антның җәзасы;

**Нәрсә ул ураза?**

Ураза - ул таң атканнан алып кояш батканчыга кадәр ашау-эчүдән һәм башка уразаны боза торган нәрсәләрдән тыелып, Аллаһка гыйбәдәт кылу.

## Уразаның ике әркәне бар:

### 1 Ният

| Мөстәхәб булган уразага ният: | Фарыз булган уразага ният: |
|---|---|
| Мөстәхәб булган уразага ниятне көннең кайсы вакытында да ясау рөхсәт ителә, ләкин аңа кадәр ашамау шарт булып тора һәм әҗер-савап ният ясаган вакыттан башланачак. | Фарыз булган ураза тотуны төннән ниятләргә кирәк, ягъни таң атканчыга кадәр. Шулай ук рамазан аеның башында да ниятләү җитә. Ниятнең урыны йөрәктә һәм тавыш белә әйту бидгать була. |

### 2 Уразаны боза торган нәрсәләрдән тыелу.



**Бу нәрсәләр уразаны боза:**

1-Белә торып ашау һәм эчү, әгәр онытылып ашалса, ураза бозылмый;
2-Якынлык кылу, әгәр уразада булган килеш якынлык кылына икән, аның җәзасы туктаусыз ике ай ураза тоту;
3-Мәнинең чыгуы;
4-Туклыклы уколлар сыман ашау-эчүне алмаштыра торган нәрсәләр;
5-Хиджама ясау; 6-Үзеңне үзең костыру;
7-Күрем көннәре сәбәпле, я инде бала туу сәбәпле кан чыгу.

**Ураза вакытында кайбер рөхсәт ителгән нәрсәләр:**

- Пешерүчегә ризыкны кабып карау;
- төкерекне йоту;
- юыну;
- хуш исләнү;
- суыну.

## Уразаның үәҗиб булуының шартлары:

1. Ислам;
2. Акыл;
3. Балигъ яшенә җиту, ләкин балигъ яшенә җитмәгән балаларны да ураза тотырга чакырырга кирәк;
4. Сәфәрдә булмау, чөнки сәфәрдә булучыга ураза үәҗиб түгел, ләкин авыр булмаса, шушы айның фазыйләтен ычкындырмас өчен, сәфәрдә дә уразасын тотса була;
5. Сау-сәламәт булу;
6. Күрем көннәрендә булмау.

**Ураза тотучыга харам булып тора:**

1 - Төкерекне авыз ачу нияте белән йоту;
2 - Уразаны бозуга китерә торган үбү;
3 - Тыелган сүзләр сөйләү һәм гамәлләр кылу;
4 - Әдепсезлек күрсәтү;
5 - Авыз ачмыйча ике көн рәттән ураза тоту.

**Уразада мәкрүһ булган нәрсәләр:**

1-Авыз-борынны чәйкаганда суны тирәнгә җибәрмәү;
2-Бер сәбәпсез ризыкны кабып карау.


Хаҗ кылу тәртибе.
Татарча
التترية
هيئة سرحان
1
Ихрам
Хаҗ кылырга дип ният кылу
Шәм һәм Миср әһелләренең микате (Хаҗ кылырга ниятләү урыны) – әл-Җүхфә 186 км
Мәдинә ягыннан хаҗ кылырга чыгучыларның микате (Хаҗ кылырга ниятләү урыны) – Зуль-Хулейфа 420 км
Ирак ягыннан хаҗ кылырга дип керүчеләрнең микате (Хаҗ кылырга ниятләү урыны) – Зәтуль-Гырк 98км
Нәҗдә әһелләренең микате (Хаҗ кылырга ниятләү урыннары) – Карнуль-Мәнәзил 99км.
Йәмән әһелләренең микате (Хаҗ кылырга ниятләү урыннары) – Яләмләм 99 км.
Самолетта очып килүчеләр күктә булган вакытта микатка иң якын булган һавадагы нокташа ихрамга керәләр.
2
Килгәч кылына торган таваф.
Ахыры
Башы
7 Җиде тапкыр кара таштан алып кара ташка хәтле әйләнә
Ике яшел күрсәткечкә хәтле һәм алардан соң атлап бара, ә алар арасында булган юлны бик тиз иттереп чаба һәм бу ир-атларга гына хас.
Сафа
Мәрва
Сафа һәм Мәрва арасында чабу
3
Тугызынчы төн
Минада төн үткәрү.
4
Монда 8нче көндә өйлә,икенде ахшам һәм ястү намазлары һәм 9нчы көндә иртәнге намаз укыла.
9нчы көн
Гәрафәттә тору.
5
һәм ул 9нчы көннең өйлә намазыннан соң башлана 10нчы көннең иртәнгә намазына хәтле.
Монда өйлә һәм Икенде намазлары берләштерелеп һәм кыскартылып укыла.
Унынчы төн.
Муздалифада төн үткәрү.
6
Монда 9нчы көнне ахшам һәм ястү намазлары укыла. һәм 10нчы көнне иртәнге намаз укыла
10нчы көн
Зур (олы) җәмәратта җиде таш атыла.
7
Зәүүәл вакыты үткәннән соң (ягъни өйлә вакыты кергәч) кече җәмәратка, соңыннан уртача җәмәратка, шуннан соң олы җәмәратка таш ату.
9
10нчы көн
Чәчне кыру яки кыскарту
Чәч кыскарту яки кырып ташлау ир-атлар өчен һәм хатын-кызлар чәчләрен бармак бөесе кадәр кыскарталар.
8
10нчы көн
Корбан чалу.
Җәмәратта ташлар ату һәм Минада төн үткәрү.
12
3нче җәмарат
2нче җәмарат
1нче җәмарат
Дога кылу урыны.
Дога кылу урыны.
11нче, 12нче һәм 13нче көннәр (соңга калганнар өчен).
10нчы көн
Хаҗ тавафын кылу
10
13
Саубуллашу тавафы.
һәм бу тавафтан күремле һәм бала тапканнан соң нифаслы хатын-кызлар бушыйлар.
Сафа һәм марва арасында чабу
11
Хаҗ нигезләре: кем дә кем берәр нигезне эшләми калдырса, аның хаҗы шунсыз кабул булмый
Хаҗның вәҗибәтләре: кем дә кем хаҗның вәҗиб гамәлен калдырса, хайван чалырга тиеш була
alsarhaan.com
sarhaan.com

# Гөмрә кылу тәртибе

Татарча التترية




## Ихрам вакытында тыелган нәрсәләр:

1. Баштан чәчне һәм шулай ук тәннән йонны алу
2. Тырнак кисү
3. Хуш исле майлар куллану
4. Үзең өчен һәм башкалар өчен никах ясау
5. Хатын-кызлар белән якынлык кылу
6. Җирдәге кыргый хәйваннарны аулап үтерү

**Ирләр өчен генә тыелган нәрсәләр:**

1. Тәнгә я инде берәр әгъзага яраклы итеп тегелгән кием кию.
2. Башны баш киеме белән, яисә чүпрәк белән каплау

**Хатын-кызларга гына тыелган нәрсәләр:**

1. Никаб белән битне каплау, ләкин чит ир-атлар булса, кием белән, я инде башка нәрсә белән битне каплау рөхсәт ителә
2. Кулга бишбармак кию

## Гөмрә кылганда мөстәхәб булган гәмәлләр:

1. Ихрамга керү алдыннан тырнакларны кисү һәм тиешле булган урыннада тән йоннарын алу.
2. Ихрамга керү алдыннан госел алу.
3. Ир кешеләргә тәннәрен хуш исле майлар белә сөртү.
4. Тәнне ак төсле изар һәм рида белән урау.
5. Ихрамга кергәч тәлбия әйтү: “Ләббәй-кә-Ллааһүммә ләббәй-к. Ләббәй-кә ләә шәрикә лә-кә ләббәй-к. Иннә-лхәмду үә-ннигмәтү лә-кә үә-лмүлк. Лә шәри-кә Ләк”.
6. Таваф вакытында ир кешеләрнең уң иң башларын ачу.
7. Кара ташны үбү.
8. Беренче өч түгәрәкне тиз-тиз адымнар белә үтү.
9. Ибраһим урыны артында ике ракагәть намаз уку.

**"БӘХЕТЛЕ ТОРМЫШНЫҢ ФАЙДАЛЫ КАГЫЙДӘЛӘРЕ"**

**Автор: Габдеррахман ибн Насыр Әс-Саади (1307-1376 һ.е.). Үз вакытының бөек галимнәренең һәм имамнарының берсе.**

1 Аллаһка иман китерү һәм изге гамәлләр кылу. Иман китерү Бөек Аллаһ тәкъдир кылган нәрсәләргә сабыр, талымсыз һәм булганына кәнәгать булырга ярдәм итә.

2. Аллаһның мәхлукатларына карата сүзләрдә дә, гамәлләрдә дә чагыла торган яхшы мөнәсәбәт. Чөнки яхшылык яхшылык тудыра һәм явызлыкны юк итә.

3. Файдалы эшләр яисә белемнәр белән мәшгуль булу. Бу синең йөрәгеңне аны борчый торган нәрсәләрдән читкә юнәлтеп торыр.

4. Бүгенге көн хакында уйла. Үткән нәрсәләр өчен кайгырма һәм уйларыңны булачак нәрсәләр  хакында фикерләп борчыма. Пәйгамбәр, Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын, кайгы һәм борчулардан саклауны сорап Аллаһка мөрәҗәгать итә торган булган.

5. Бөек Аллаһны ешрак зикер итү. Аллаһны искә төшерү йөрәкне тынычландыра һәм аңа тынычлык бирә.

6. Аллаһтан бирелгән билгеле һәм яшерен булган нигъмәтләр хакында фикер йөртү. Бу бит кешене шөкер кылырга этәрә һәм борчуларны оныттыра.

7. Үзеңнән дә начаррак хәлдә булган кешегә кара. Бу исә, бар булган нәрсәләрең өчен Аллаһны мактый башлавыңа сәбәп булачак һәм сине кайгы-борчулардан арындырачак.

8. Булып узган нәрсәне оныт. Үткәнне кире кайтара алмыйсың, ә үткәннәр турында борчылу бары комачаулый гына һәм буш гамәл булып тора.

9. Биек булган Аллаһка дога белән дәш. Мәсәлән, хәдистә әйтелгәнчә, синең дини, дөньяви һәм ахирәт тормышыңны төзәтсен дип Аллаһка дога белән дәшү.

10. Мөмкин булган нәтиҗәләрнең иң начарына әзерлән. Әгәр бәхетсезлеккә дучар булсаң, вакыйгалар үсешенең иң начар вариантын алдан ук исәпкә ал. Чөнки мондый адым, әгәр дә бу хәл шулай була калса, хәлнең җиңеләюенә сәбәп булачак. Әгәр дә инде бу хәл булса, ул чагында әлеге проблеманы юкка чыгарырга омтыл.

11. Буш хыяллар һәм күзаллаулар белән мавыкма. Бу иллюзиялар начар уйларга китерергә һәм начар нәтиҗәләргә сәбәп булырга мөмкин. Моннан тыш, алар борчылуның һәм чирләрнең сәбәбе.

12. Синең йөрәгең Аллаһка таянсын һәм Аңа тәвәккәлләсен. "Кем Аллаһка тәвәккәл кыла - Ул аңа җитә".
13. Кешеләрнең хаталарына һәм алар тарафыннан кылына торган күңелсезлекләргә сабыр бул. Барлык кешеләрнең дә кимчелекләре яисә сиңа охшамый торган сыйфатлары бар. Син исә аларга икенче яктан - яхшы яктан кара.
14. Юк-барга һәм кечкенә генә хәлләргә игътибар итмә. Әгәр дә син үзеңне бәхетсезлекләрне һәм авыр хәлләрне түземлек белән кичерергә өйрәтсәң, зур булмаган хәлләргә син тагын да зур түземлек белән карарга тиешсең.
15. Гомер кыска. Аның тиз үтүчән булуына да карамастан, чын тормыш - бәхет һәм тынычлык белән тулы. Шулай булгач, булган бәла-казалар хакында борчылып, уйланып аны тагын да кыскартма.
16. Күпчелек тынычсызлыкларның һәм борчуларның нигезе юк һәм алар уйдырма булып торалар. Син борчылган нәрсәләрнең күбесе тормышка ашмады. Шуңа күрә, көчлерәк булган фикер өстеннән ялган булган фаразларга өстен чыгарга рөхсәт итмә.
17. Кешеләр китергән үпкәләр өчен кәефеңне төшермә. Асылда, бу рәнҗүләр аларны кылган кешеләрнең үзләренә генә зыян сала. Әмма, әгәр дә син моңа әһәмият бирә калсаң, ул чагында зарары сиңа да кагылыр.
18. Синең тормышың синең фикерләреңә туры килә. Әгәр дә синең фикерләрең динеңдә дә, дөньяви тормышыңда да файда китерә торган нәрсәләр белән мәшгуль булса, ул чагында тормышың яхшы һәм бәхетле булачак. Әгәр дә юк икән, нәтиҗә дә тиешенчә булачак.
19. Кешеләрдән рәхмәт сүзләре көтмә. Әгәр дә син берәрсенә яхшылык эшләдең икән, син аның алдында бурычлымы, юкмы - анысы мөһим түгел, шушы яхшы гамәлең Аллаһ белән икегезнең арасында калырга тиеш. Шуңа күрә дә, читтән рәхмәт сүзләре ишетелмәгәнгә игътибар итмә.
20. Үзең өчен файдалы булган әйбер белән мәшгулъ бул. Зарарлы шөгыльләр сине борчуга һәм тынычсызлыкка китерә, шулай булгач, файдалы эшләр белән шөгыльлән.
21. Үз эшләреңне һәм проблемаларыңны хәл итүне кичектермә. Әгәр дә син аларны шундук хәл итмәсәң, ул чагында алар алдагы эшләргә кушылачак, ә аларга - яңа эшләр һәм шулай итеп, син үз алдыңа куйган максатларны башкарып чыга алмаячаксың.
22. Приоритетларны бүл. Үз алдыңа куйган бурычларны мөһимлеге дәрәҗәсе буенча үти башла. Күңелсезлек биләп алмасын өчен, үзеңә ошаган эшне сайлап ал. Компетентлы кешеләр белән киңәшләш, чөнки киңәшләшә торган кеше үкенмәячәк.

Татар - تتري - 01/50




# Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ кем ул һәм без аның турында нәрсә беләбез?

Шәйх Хәйсам Сархан аңлатмасы

Пәйгамбәребез мәчете каршындагы институтта укытучы булып эшләгән һәм Сөннәт мәдрәсәсе мөшрифе

sarhaan.com

Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ кем ул һәм без аның турында нәрсә беләбез?

- Ул 1400 елдан бирле барлык кешеләрнең хокукларын яклаган кеше.

- Ир-атларны, хатын-кызларны, балаларны һәм көчсезләрне яклаган.

-Хайваннарның һәм үсемлекләрнең хокукларын яклаган һәм үзебез яшәгән җиребезне кайгыртырга өндәгән.

- Ул әдәпле булырга һәм туганнар һәм күршеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне яхшыртырга әмер иткән.

- Мөселманнар белән мөселман булмаганнар арасында бергә яшәүнең нигезләрен җайлаган.

- Ата белән Анага үз балаларына зур хокукларга ия булуын гарантияләүче гаилә мөнәсәбәтләрен оештырган.

## Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ кем ул һәм без аның турында нәрсә беләбез?

- Ул золымлыкны тыйган һәм гаделлеккә, мәхәббәткә, бердәмлеккә һәм хезмәттәшлеккә өндәгән.

- Ул мохтаҗларга булышырга, авыруларны зиярат кылырга, хәлләрен белергә, кешеләрне хөрмәт итергә һәм киңәш сораучыга киңәш бирергә чакырган.

- Мөселманнарны урлау, алдау, үтерү һәм гаделсезлек кебек начар гадәтләрдән тыйган.

- Ул безнең тормышыбызны һәм начар характерыбызны яхшы якка үзгәрткән.

- Мөселманны урламаска өйрәткән.

- Мөселманны ялганламаска өйрәткән

- Мөселманны спиртлы эчемлекләр эчмәскә өйрәткән.

Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ кем ул һәм без аның турында нәрсә беләбез?

- Мөселманны зина кылмаска өйрәткән.

- Мөселманны алдамаска өйрәткән.

- Мөселманны гаепсезләр белән көрәшмәскә өйрәткән

- Мөселманны күршесенә зыян китермәскә өйрәткән, ул мөселманмы яки имансыз булсада.

- Мөселманны әти-әнисенә хөрмәт итәргә һәм аның диненнән булмаса да аларга ярдәм итәргә өндәгән.

- Мөселманны балаларга, хатын-кызларга, зәгыйфьләргә һәм картларга игелекле булырга чакырган.

- Мөселманны кешеләрне яки хайваннарны җәберләмәскә һәм әйләнә-тирә мохитне бозмаска кушкан.

## Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ кем ул һәм без аның турында нәрсә беләбез?

-Мөселманны шәфкатьле булырга, хатынын яратырга, гомеренең соңгы көненә кадәр балаларын кайгыртучан булырга өндәгән.

- Мөселманга аның балалары белән мөнәсәбәтләре балигллык яшьтән соң өзмәскә чакырган.

- Һәрбер мөселман Мөхәммәдне ﷺ барлык җан ияләренә караганда катырак ярата.

- Моны безгә Муса һәм Гайсә пәйгамбәрләр ирештерде аларга Аллаһның сәләме булсын.

- Һәрбер мөселман Муса белән Гайсәне ярата, аларга Аллаһнын сәламе булсын, һәм алар иң фазыйләтле пәйгамбәрләр арасында дип саныйлар.

- Аллаһ тагәлә Мөхәммәдне ﷺ гарәпләргә һәм гарәп булмаганнарга җибәрде

Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ кем ул һәм без аның турында нәрсә беләбез?

– Аның динендә гарәп белән гарәп булмаганнар арасында диннарлыгында бер нинди аерма юк иллә дә мәгәр тәкъвалыкта гына.

– Ул Мөхәммәд, Аллаһның Расүле ﷺ.

– Ә беләсезме ни өчен барлык мөселманнар Мөхәммәдне ﷺ яраталар?

– Ә беләсезме, Мөхәммәд ﷺ мөселманнар өчен нәрсәне аңлата?

Мөхәммәд ﷺ пәйгамбәр турында күбрәк белергә һәм өйрәнергә теләсәң ...

Шәйхнын сайты

sarhaan.com

Сөннәт мәдрәсәсе

mahadsunnah.com